СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

24.11.2025 с. Верхний Услон № 2-17

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Олы Меми авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре
үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Олы Меми авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 12 маендагы 591/о номерлы боерыгы кабул ителүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Югары Ослан муниципаль районы Советы

карар итте:

1. "Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында" 2021 елның 27 декабрендәге 18-233 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Советының икътисади үсеш, экология, табигый ресурслар һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А. Варакин